| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.03.2019 № 33-п

Ел саен үткәрелүче “Закон территориясе” республика конкурсының муниципаль этабын үткәрү турында

Җәмәгать тәртибен тәэмин итүгә, яшүсмерләргә һәм яшьләргә хокук тәрбиясе бирүгә, хокук бозуларны кисәтүгә сизелерлек өлеш керткән муниципаль районнарның, авыл җирлекләренең, оешма һәм предприятие, мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренең, физик затларның уңай тәҗрибәсен иҗтимагый тану, бүләкләү һәм тарату максатыннан һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Ел саен үткәрелүче Закон территориясе” республика конкурсын үткәрү турында” 2012 елның 20 февралендәге 135 нче карарын үтәү йөзеннән,

КАРАР БИРӘМ:

1. Саба муниципаль районында “Ел саен үткәрелүче “Закон территориясе” республика конкурсының (алга таба – конкурс) муниципаль этабын үткәрергә.

2. Түбәндәге составта “Ел саен үткәрелүче “Закон территориясе” республика конкурсы муниципаль этабының конкурс комиссиясен төзергә:

Закирҗанов Р.Р – Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасары, комиссия рәисе;

Сабирова А.Р. - Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Административ комиссиясе баш белгече, комиссия секретаре;

Комиссия әгъзалары:

Баһманов М.М. - Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары - икътисад бүлеге начальнигы;

Ишниязов М.Р. - Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе;

Исмәгыйлов В.Ш. – Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге начальнигы (килешенү буенча);

Миникаев А.И. - Саба муниципаль район Советының юридик бүлеге начальнигы;

Шәйдуллин Л.И. - Саба муниципаль район Башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе.

3. Авыл җирлеге Башлыкларына, идарә һәм бүлек начальникларына, гомуми белем бирү учреждениеләре, шулай ук урта һөнәри белем учреждениеләре директорларына, шәхси сак предприятиеләре, җәмәгать оешмалары җитәкчеләренә “Закон территориясе” конкурсының муниципаль этабында катнашырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.Р. Закирҗановка йөкләргә.

Р.Н. Минниханов